ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь, 2016 ел № 11/11

**Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/17 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре Хакименең исемле стипендияләрен гамәлгә кую тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Шәһәр Уставының 28 маддәсе һәм Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге «Яр Чаллы шәһәренең бүлəкләре хакында Нигезнамәне раслау турында» 25/23 санлы Карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/17 санлы Карары (Шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге 37/5, 2010 елның 26 маендагы 50/9 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре Хакименең исемле стипендияләрен гамәлгә кую тәртибе турында Нигезнамәгә, 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«9. Стипендияләр түбәндәге санда һәм күләмдә билгеләнә:

1) спорт өлкәсендә – һәркайсы 1000 сум күләмендә булган 10 стипендия;

2) сәнгать өлкәсендә – һәркайсы 1000 сум күләмендә булган 10 стипендия;

3) җәмәгатьчелек эшчәнлеге өлкәсендә – һәркайсы 1000 сум күләмендә булган 20 стипендия.

2. Әлеге Карар 2017 елның 1 январеннән үз көченә керә.

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев